**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ КАРАР __________

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында гражданлык оборонасының әзерлеген арттыру турында**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 20 октябрендәге 751 номерлы Указын һәм Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы җитәкчесе - Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 21 октябрендәге 8 номерлы боерыгын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 20 октябрендәге 751 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Президенты-гражданнар оборонасы җитәкчесенең 2022 елның 21 октябрендәге 8 номерлы (алга таба оператив штаб) боерыгы белән каралган чараларны гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының оператив штабын төзергә һәм аның составын (1 нче кушымта) расларга.

2. Актаныш муниципаль районы территориясендә агымдагы вәзгыятьне һәм ихтимал хәвеф-хәтәрне исәпкә алып, оператив штабка Актаныш муниципаль районы гражданнар оборонасының әзерлеген арттыру буенча чаралар күрүне тәэмин итәргә (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru  һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
________2022 №____
1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районы оператив штабының составы

Ильясов Р.А. - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Актаныш муниципаль районының оператив штаб җитәкчесе;

Габдулхаев И.И. - Актаныш муниципаль районы Башлыгы урынбасары;

Гарипов Р.И. - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары;

Сираева Л.Р. - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары;

Шәрифьянов И.И. - Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Актаныш 103 янгын сагы бүлеге башлыгы;

Хәмитов Р.Р. - ТР Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы гражданнар оборонасы өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәүче консультанты (Актаныш муниципаль районы буенча)

Багавиев Р.З. - Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлеге башлыгы;

Хөсәенов Р.В.- Актаныш муниципаль районының “Гражданнар оборонасы идарәсе” җитәкчесе.

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
________2022 №________
2 нче кушымта

Актаныш муниципаль районында гражданнар оборонасының әзерлеген арттыру чаралары

| № т/б | Чаралар исеме | Җаваплы | Вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | Граждан оборонасы өлкәсендә планлаштырыла торган документларны төгәлләштерү:<br>- Гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы, гражданнар оборонасына әзерлек планы<br>- Районның коткару хезмәтләре гражданлык оборонасы чараларын тәэмин итү планнары | Район предприятие ләре һәм оешмалары җитәкчеләре, Районның коткару хезмәтләре җитәкчеләре | ел саен |
| 2. | Гражданнар оборонасы буенча дәресләр (инструктажлар) уздыруны һәм граждан оборонасы сигналларын, җитештерүдән аерылмыйча эшләүче персонал белән эшләгәндә, персоналның гамәлләрен оештырырга | Район предприятие ләре һәм оешмалары җитәкчеләре | ай саен |
| 3. | Гражданнар оборонасы һәм эшләмәүче халык белән гражданнар оборонасы сигналларын алганда халык гамәлләре буенча дәресләр (инструктажлар) уздыруны оештырырга | Районның авыл җирлекләре башлыклары, ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы ның ГО өлкәсендә әйдәп баручы консультанты (Актаныш районы буенча) “Актаныш муниципаль районының гражданлык яклау идарәсе” җитәкчесе, район укыту-консультация пунктлары башлыклары (УКП) | Ай саен, шул исәптән УКП планы буенча |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Граждан оборонасы буенча дәресләр (инструктажлар) уздыруны һәм гражданнар оборонасы сигналларын торак милекчеләре ширкәтләре рәисләре һәм йортлар буенча өлкәннәр белән алганда эшләрне оештырырга | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы ның ГО өлкәсендә әйдәп баручы консультанты (Актаныш районы буенча) | 10.11.2022 елга кадәр |
| 5. | Эшләмәүче персоналга саклау корылмаларында ( җир асты киңлегенең башка корылмаларында) саклану ысуллары һәм урыннары буенча мәгълүмат бирүне оештырырга | Район предприятие ләре һәм оешмалары җитәкчеләре, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары, ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы ның ГО өлкәсендә әйдәп баручы консультанты (Актаныш районы буенча) | УКП планы буенча |
| 6. | Районның критик мөһим оешмаларының тотрыклы эшләвенә ярдәм итү буенча чараларны раслау | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, район предприятие ләре һәм оешмалары җитәкчеләре | 17.11.2022 елга кадәр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Эвакуацияләнә торган халыкны кабул итү чараларын ачыклау | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, районның авыл җирлекләре башлыклары, ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы ның ГО өлкәсендә әйдәп баручы консультанты (Актаныш районы буенча) | 01.11.2022 елга кадәр |
| 8. | Гражданнар оборонасы максатларында булдырылган матди - техник, азык-төлек, медицина һәм башка чараларның запасларының булуы һәм аларны куллану тәртибен ачыкларга | Район предприятие ләре һәм оешмалары җитәкчеләре, районның коткару хезмәтләре җитәкчеләре | 20.11.2022 елга кадәр |
| 9. | Халыкка хәбәр итүнең муниципаль һәм объектлы (локаль) системаларының әзерлеген тикшерергә | Предприятие җитәкчеләре, районның авыл җирлекләре башлыклары, Актаныш муниципаль районының “Гражданнар яклау идарәсе” (район ЕДДС) җитәкчесе | 01.11.2022 елга кадәр |
| 10 | Саклагыч корылмаларның яшерен кабул итүгә әзерлеген тәэмин итү | Район предприятие ләре һәм оешмалары җитәкчеләре, ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы ның ГО өлкәсендә әйдәп баручы консультанты | 16.11.2022 елга кадәр. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | (Актаныш районы буенча) | |
| 11 | Җир асты киңлегенең башка корылмаларына (торак йорт подвалларына) ревизия үткәрергә, шулай ук гражданнар оборонасы сигналы буенча халыкны яшерү өчен файдалану максатыннан аларны кирәкле мөлкәт белән тәэмин итүне планлаштырырга | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары, ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы өлкәсендә ОРП әйдәп баручы консультанты (Актаныш районы буенча), ТСЖ(торак милекчеләре ширкәте) рәисләре | 20.11.2022 елга кадәр |
| 12. | Энергия белән тәэмин итүнең, җылылык белән тәэмин итүнең автоном чыганакларының әзерлеген тикшерергә | Район предприятие ләре һәм оешмалары җитәкчеләре | 10.11.2022 елга кадәр |
| 13. | Районның коткару хезмәтләрен һәм гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итү буенча штаттан тыш оешмаларны билгеләү буенча әзерлекне арттыруга һәм гамәлләргә юнәлдерелгән чаралар оештырырга | Актаныш муниципаль районының оператив штабы | 09.11.2022 елга кадәр. |